# Задания заключительного тура Акмуллинской олимпиады по татарскому языку и литературе для учащихся 10-11 классов, студентов СПО

1. Буш урыннарга исемнәрнең данә исәбен белдергән сүзләрне куегыз (5 б):

| | |
|---|---|
| 1 капчык ... шикәр | 1 кочак ... салам |
| икмәк ... валчыгы | 1 тотам ... арыш көлтәсе |
| 1 уч ... җиләк | бодай .... көлтәсе |
| салам ... өеме | 2 кап ... шырпы |
| 10 баш ... кәбестә | чәчәк ... бәйләме |

2. Саннар артына яшеренгән мәкальне табып языгыз (10 б).

1, 12 38, 13, 23, 34, 21, 23, 13, 1, 16, 6, 1 12, 18, 14, 6, 34, 10 13, 25, 7, 36, 15, 11.

Ай яктырткында йолдыз күренми.

3. Канатлы сүзләрне рус теленә тәрҗемә итегез: (12 б)

Ахиллес үкчәсе Ахиллесова пята,

Шөкатьсез үрдәк баласы гадкий утёнок,

Дары мичкәсендә дары бар әле есть порох в пороховницах,

Очкыннан ялкын кабына 1. из искры возгорится пламя; 2. как на пороховой бочке

Крокодил күз яше крокодиловы слезы,

Аю хезмәте күрсәтү оказать медвежью услугу.

4. Түбәндәге формулаларга туры килгән сандхи очракларына 1-әр мисал китерегез (3+3=6):

е + ә = ә килде әле = ә

ы+у=у куйды уе = у

5. Дөрес җавапны билгеләгез (4 б.):

*Бергә алар язгы урман һавасы суладылар, яр буенда саргылт тал ПИПИЛӘРЕ өзделәр* (Н.Фәттах). Җөмләдә аерып бирелгән сүз:

– профессионализм
– архаизм
– диалектизм
– неологизм

Алар билгеле бер формага буйсынган булалар. Аларда мәҗбүри җөмлә калыплары, сүзтезмәләр, тәгъбирләр кулланыла, алардан зур төгәллек сорала.

– матур әдәбият әсәрләре
– рәсми эш кәгазьләре
– публицистик әсәрләр
– драма әсәрләре

Бирелгән кереш сүзләр нинди мәгънә белдерәләр?
*ихтимал, күрәсең, бәлки, ахрысы, ахры*

- билгесезлекне
- үтенүне
- сөйләүченең төрле тойгысын
- фикер эзлеклелеген

Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” әсәренең тулы текстын беренче булып кульязмада әзерләгән әдип:

- С.Сараи
- Г.Утыз Имәни
- Й.Баласагунлы
- Колшәриф

6. Дөрес җавапларны билгеләгез: (3 б)
1. Әсәрләрнең жанрын языгыз:
“Сөннәтче бабай” повесть, автор хикәя дип атый
“Беренче театр” комедия
“Сак-Сок” бәет

7. Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» драмасында автор югары күтәргән сыйфатлар (1 сыйфат – 1 б. =5 б.).

1. туры сүзлелек
2. батырлык, курыкусызлык
3. тугрылык, тәвәкәллек
4. тормышны ярату, ярата белү
5. наянлык, кешелеклелек

8. М. Акмулла “Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт берлән” дип язган. Автор турында 5 факт яз (10 б.)

1. мулла гаиләсендә, 16 бала арасында үсә,
2. Стәрлебашта Шиһабетдин Зәкидә укый,
3 әтисе белән, гаиләсе белән аерылыша,
4. Казах далаларында балалар укыта,
5. кулга алынып, 4 ел төрмәдә була.

9. Җәяләрне ачып, дөрес языгыз (5 б).

(1)Сулар ага... (2) Җир (йөзендә) йөзендә сулар бер (туктаусыз) бертуктаусыз агалар (да) агалар. (3)Җәй агалар, яз агалар, көз агалар... (4)Агым сулар кешеләрнең чир (чорларын) чир-чорларын кайгыларын, языкларын алалар (да) алалар да еракларга, упкыннарга, чоңгылларга ыргыталар. (5)Агым сулар, җир (өстенең) өстенең чүп (чарларын) чүп-чарларын юып алып, үзләрендә юк итәләр. (6)Шулай ел (да) ел да җир яңара, җир яшәрә.

(7)Җир яңара, җир яшәрә... (8)Өзелмичә, туктамыйча, бөек Чулман кебек, Әтил кебек, көн (төн) көн-төн җирдә тормыш ага.

(9)Яз килде, яз!... 10)Киң Чулманга – кояш белән, ай (йолдызлар) ай-йолдызлар белән яшьтәш Чулманга ашыгып төрле ~~(яктан)~~ сулар ага...(Н. Фәттах).

10. Бирелгән өзек нинди әсәрдән? (2 б.) „Итил суы ага торур"

11. Түбәндәге тел күренешләре булган җөмлә номерларын куярга (5 б):

1) ялгызлык исемнәре
2) парлы сүзләр
3) гөнаһ сүзенә синоним
4) юклык формасындагы фигыль
5) вакыт мәгънәсен белдергән исем

| 1) | 2) | 3) | 4) | 5) |
|---|---|---|---|---|
| 8, 10 | 4, 5, 8, 10 | 4 | 8 | 3, 6, 8, 9 |

12. 5нче җөмләдә хәбәрнең төре (3 б.) юк итәләр

13. Өзекне дәвам итеп эссе языгыз. Күләме 200 сүздән ким булмаска тиеш (30 б.)

Омтылэрең өзелмәндә
Агым суларга кара...

Агымсулар кемне сагышларын алып китә микән? Җирне агарткан төсле, күңелне дә агарта микән?

Быелгы җәй минем өчен сәяхәтләргә бай булды. Иң кадерле хатирәләремнең берсе булып, Болгарга бару саклана. Андагы изге җиргә аяк басу, мең еллык тарихны үз күзләрең белән күрү, күкрәк тутырып саф һавасын сулау бик күңелле хисләр уята, сокландыра, уйландыра. Ул җирдә бар нәрсә шул чакта туктап калган кебек. Тик мәңге хәрәкәттә булган бөек Идел генә бар серләрне саклый төсле. Ул елга гына булганнарга тере шаһит кебек тоела...

Тарих белән очрашудан соң бер фикер туды миндә: кеше гомере – бер мизгел. Аны изге гамәлләр, файдалы эшләр, дөреслек белән кичерергә кирәк.

Дөньядагы изге урыннарга бару, кеше кулы белән тудырылган могҗизаларны күрү, табигатьнең сихри гүзәллеге – күңелләрне

сафландыра, чистарта, көч бирә.

Шундый тагын бер кадерле урынга әверелде минем өчен Казандагы Кол Шәриф мәчете. Ул мәһабәт бина нур чәчүче, мөселманнарны дөрес юлга бастыручы Аллаһ йорты.

Дин, мәхәббәт, намус, батырлык, тугрылык һ.б. кебек төшенчәләргә кешеләр ясап куйган чикләр тәэсир итмидер. Шуңа да кайда гына яшәсәк тә, нинди гаиләдә үссәк тә, безне берләштерә торган бу төшенчәләр бар.

Никадәр авыр булса да,
Агымсу юлын таба...

Кешелек агымсуга карап, гомернең чикле һәм бик тиз үтүен аңласын иде. Гонаһларына тәүбә итеп, матурлыкка омтылса иде...

Әйе, бәлки мин бу язуымда дөньяга ал күзлек аша каравымны күрсәткәнмендер. Ләкин мин әкиятләргә ышанучы кыз. Яхшылык кына җиңәргә тиеш, дип уйлыйм. Юраганың юш килә, ди бит халык. Без нәрсә уйлыйбыз, алдыбызга шул чыгачак, монсы-хак. Шуңа күрә, күңелебезнең чисталыгы турында кайгыртыйк. Уй көче бәлән күп көче бирдер. Мәхлүкне күбәләк гомере төсле, бар да безнең кулда.

Ахырда шуны әйтәсем килә, агымсу юлын таба, кеше дә аннан мисал алып, табигатьтән көч алып, үзенә дөрес бәя биреп, яшәсен иде.